Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

КАРАР Постановление

№ 23 14.09.2022

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 1 апрелендәге 8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (28.04.2021 № 10).

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 1 апрелендәге 8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү (28.04.2021 № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта "муниципаль программаларның структур элементлары" сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 12 пунктта:

а) икенче абзацта "Муниципаль программаларның структур элементлары турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорда нисбәте белән характерлана."

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Чәчәкле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Фәисханов